**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 декабрендәге 4710 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 26 июлендәге 4000 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының санитария-эпидемиягә каршы комиссиясе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының санитария-эпидемиягә каршы комиссиясе структурасын һәм бурычларын оптимальләштерүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 26 июлендәге 4000 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының санитария-эпидемиягә каршы комиссиясе турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 20 мартындагы 849 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының санитария-эпидемиягә каршы комиссиясе турындагы нигезләмәне расларга»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 2(1) пункт өстәргә:

«2(1). Санитария-эпидемиягә каршы комиссиянең составы Казан шәһәре Башкарма комитетының аерым карары белән раслана дип билгеләргә»;

1.3. 1 номерлы кушымтада «1 номерлы кушымта» сүзләрен «кушымта» сүзенә алмаштырырга;

1.4. 2 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**